# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О порядке осуществления муниципального земельного контроля на территории Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
25 сентября 2015 года

### Статья 1. **Муниципальный земельный контроль**

Под муниципальным земельным контролем понимается деятельность органов местного самоуправления по контролю за соблюдением органами государственной власти, органами местного самоуправления, юридическими лицами, индивидуальными предпринимателями, гражданами в отношении объектов земельных отношений требований законодательства Российской Федерации, законодательства Республики Татарстан, за нарушение которых законодательством Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан предусмотрена административная и иная ответственность.

### Статья 2. **Осуществление муниципального земельного контроля в отношении органов государственной власти, органов местного самоуправления, юридических лиц, индивидуальных предпринимателей**

1. Муниципальный земельный контроль в отношении юридических лиц и индивидуальных предпринимателей осуществляется в соответствии с Федеральным законом от 26 декабря 2008 года № 294-ФЗ «О защите прав юридических лиц и индивидуальных предпринимателей при осуществлении государственного контроля (надзора) и муниципального контроля» с учетом особенностей, установленных Земельным кодексом Российской Федерации.
2. Муниципальный земельный контроль в отношении органов государственной власти и органов местного самоуправления осуществляется в порядке, установленном для осуществления муниципального земельного контроля в отношении юридических лиц и индивидуальных предпринимателей.

Статья 3. **Осуществление муниципального земельного контроля в отношении граждан**

1. Муниципальный земельный контроль в отношении граждан осуществляется посредством проведения плановых и внеплановых проверок соблюдения гражданами требований законодательства Российской Федерации, законодательства Республики Татарстан при использовании ими объектов земельных отношений (далее – плановая проверка, внеплановая проверка).

2. Плановая проверка проводится не чаще чем один раз в три года на основании ежегодного плана проведения плановых проверок (далее – ежегодный план проверок), утверждаемого органом муниципального земельного контроля.

3. Основанием для включения плановой проверки в ежегодный план проверок является истечение трех лет со дня:

1) возникновения у гражданина права на объект земельных отношений (далее – земельный участок);

2) окончания проведения последней плановой проверки земельного участка.

4. Утвержденный ежегодный план проверок доводится до сведения заинтересованных лиц посредством его размещения на официальном сайте органа муниципального земельного контроля в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» либо иным доступным способом.

5. Внеплановая проверка проводится в случае:

1) истечения срока исполнения гражданином ранее выданного предписания об устранении выявленного нарушения требований земельного законодательства;

2) поступления в органы муниципального земельного контроля обращений и заявлений граждан, в том числе индивидуальных предпринимателей, юридических лиц, информации от органов государственной власти, органов местного самоуправления, из средств массовой информации о следующих фактах:

а) возникновение угрозы причинения вреда жизни, здоровью граждан, вреда животным, растениям, окружающей среде, объектам культурного наследия (памятникам истории и культуры) народов Российской Федерации, безопасности государства, а также угрозы чрезвычайных ситуаций природного и техногенного характера;

б) причинение вреда жизни, здоровью граждан, вреда животным, растениям, окружающей среде, объектам культурного наследия (памятникам истории и культуры) народов Российской Федерации, безопасности государства, а также возникновение чрезвычайных ситуаций природного и техногенного характера.

6. Указанные в пункте 2 части 5 настоящей статьи обращения и заявления, не позволяющие установить лицо, обратившееся в орган муниципального земельного контроля, а также обращения и заявления, не содержащие сведений о фактах, указанных в пункте 2 части 5 настоящей статьи, не могут служить основанием для проведения внеплановой проверки.

Статья 4. **Порядок организации проверок в рамках осуществления муниципального земельного контроля в отношении граждан**

1. Проверки в рамках осуществления муниципального земельного контроля в отношении граждан проводятся на основании распоряжения (приказа) руководителя (заместителя руководителя) органа муниципального земельного контроля о назначении проверки.

2. В распоряжении (приказе) руководителя (заместителя руководителя) органа муниципального земельного контроля о назначении проверки указываются:

1) наименование органа муниципального земельного контроля;

2) фамилии, имена, отчества, должности должностного лица или должностных лиц, уполномоченных на проведение проверки, а также привлекаемых к проведению проверки экспертов, представителей экспертных организаций;

3) фамилия, имя, отчество гражданина, в отношении которого проводится проверка;

4) идентификационные признаки земельного участка (адрес земельного участка или при отсутствии адреса земельного участка иное описание местоположения земельного участка, его кадастровый номер, категория земель, в состав которых входит земельный участок), который является объектом проверки (далее – проверяемый земельный участок);

5) правовые основания проведения проверки;

6) вид проверки (плановая или внеплановая) и форма ее проведения (документарная или выездная);

7) перечень документов, необходимых для представления гражданином;

8) даты начала и окончания проведения проверки.

Статья 5. **Уведомление о проведении проверки в рамках осуществления муниципального земельного контроля в отношении граждан**

1. О проведении плановой проверки орган муниципального земельного контроля уведомляет гражданина не позднее трех рабочих дней до начала проведения проверки посредством направления копии распоряжения (приказа) руководителя (заместителя руководителя) органа муниципального земельного контроля о назначении плановой проверки заказным письмом с уведомлением о вручении или иным доступным способом.

2. О проведении внеплановой проверки, за исключением случая, указанного в части 3 настоящей статьи, орган муниципального земельного контроля уведомляет гражданина не менее чем за 24 часа до начала ее проведения любым доступным способом.

3. В случае если в результате нарушения гражданином требований земельного законодательства причиняется вред жизни, здоровью граждан, вред животным, растениям, окружающей среде, объектам культурного наследия (памятникам истории и культуры) народов Российской Федерации, возникает угроза безопасности государства, а также возникли или могут возникнуть чрезвычайные ситуации природного и техногенного характера, предварительное уведомление

гражданина о начале проведения внеплановой проверки не требуется. При этом отсутствие гражданина или его представителя при проведении внеплановой проверки не является препятствием для ее проведения.

Статья 6. **Формы проверок в рамках осуществления муниципального земельного контроля в отношении граждан**

1. Проверки в рамках осуществления муниципального земельного контроля в отношении граждан проводятся в документарной и (или) выездной формах, срок проведения каждой из которых не может превышать 20 рабочих дней.

2. В исключительных случаях, связанных с необходимостью проведения сложных и (или) длительных исследований, специальных экспертиз, на основании мотивированных предложений лиц, проводящих проверку, срок проверки может быть продлен распоряжением (приказом) руководителя (заместителя руководителя) органа муниципального земельного контроля, но не более чем на 20 рабочих дней.

3. Документарная проверка проводится по месту нахождения органа муниципального земельного контроля. Выездная проверка проводится по месту фактического расположения проверяемого земельного участка.

4. Предметом документарной проверки являются сведения, содержащиеся в документах, устанавливающих права и обязанности гражданина в отношении проверяемого земельного участка, а также документы, связанные с соблюдением гражданином требований земельного законодательства.

5. В процессе документарной проверки в первую очередь рассматриваются документы, имеющиеся в распоряжении органа муниципального земельного контроля, в том числе акты предыдущих проверок, материалы рассмотрения дел об административных правонарушениях и иные документы о результатах проверки, ранее проведенной в рамках осуществления муниципального земельного контроля в отношении гражданина.

6. В случае если достоверность сведений, содержащихся в документах, имеющихся в распоряжении органа муниципального земельного контроля, вызывает обоснованные сомнения либо если эти сведения не позволяют оценить соблюдение гражданином требований земельного законодательства, орган муниципального земельного контроля направляет в адрес гражданина мотивированный запрос с требованием представить необходимые для рассмотрения в ходе документарной проверки документы и пояснения. В течение 10 рабочих дней со дня получения мотивированного запроса гражданин обязан представить в орган муниципального земельного контроля указанные в запросе документы и пояснения.

7. Орган муниципального земельного контроля не вправе требовать у гражданина сведения и документы, не относящиеся к предмету документарной проверки, а также сведения и документы, которые могут быть получены этим органом от органов государственного контроля (надзора), иных органов муниципального контроля.

8. Выездная проверка проводится в случае, если при документарной проверке не представляется возможным удостовериться в полноте и достоверности сведений, которые содержатся в имеющихся в распоряжении органа муниципального

земельного контроля документах, устанавливающих права и обязанности гражданина в отношении проверяемого земельного участка, либо оценить соблюдение гражданином требований земельного законодательства.

9. Выездная проверка начинается с предъявления служебного удостоверения должностными лицами органа муниципального земельного контроля, ознакомления гражданина с распоряжением (приказом) руководителя (заместителя руководителя) о назначении выездной проверки и с полномочиями проводящих выездную проверку лиц, а также с целями, задачами, основаниями проведения выездной проверки, видами и объемом мероприятий по контролю, составом экспертов, представителями экспертных организаций, привлекаемых к выездной проверке, со сроками и с условиями ее проведения.

10. Гражданин обязан обеспечить доступ проводящих выездную проверку должностных лиц органа муниципального земельного контроля и участвующих в выездной проверке экспертов, представителей экспертных организаций на проверяемый земельный участок.

Статья 7. **Порядок оформления результатов проверки в рамках осуществления муниципального земельного контроля в отношении граждан**

1. По результатам проверки в рамках осуществления муниципального земельного контроля в отношении граждан должностными лицами органа муниципального земельного контроля, проводящими проверку, составляется акт проверки, в котором указываются:

1) дата, время и место составления акта проверки;

2) наименование органа муниципального земельного контроля;

3) дата и номер распоряжения (приказа) руководителя (заместителя руководителя) органа муниципального земельного контроля о назначении проверки;

4) фамилии, имена, отчества и должности должностного лица или должностных лиц, проводивших проверку;

5) фамилия, имя, отчество гражданина, в отношении которого проводилась проверка;

6) фамилии, имена, отчества лиц, присутствовавших при проведении проверки и составлении акта проверки;

7) даты и время начала и окончания проверки, место проведения проверки;

8) сведения о результатах проверки, в том числе о выявленных нарушениях законодательства Российской Федерации, законодательства Республики Татарстан;

9) сведения об ознакомлении или отказе в ознакомлении с актом проверки гражданина или его представителя, присутствовавшего при проведении проверки, о наличии их подписей или об отказе от совершения ими подписей;

10) подписи должностного лица или должностных лиц, проводивших проверку.

2. Акт проверки оформляется непосредственно после завершения проверки в двух экземплярах, один из которых с копиями приложений (при их наличии) вручается гражданину или его представителю под расписку об ознакомлении либо отказе в ознакомлении с актом проверки.

3. В случае отсутствия при проведении проверки гражданина или его представителя, а также в случае их отказа дать расписку об ознакомлении либо отказе в ознакомлении с актом проверки один экземпляр акта проверки с копиями приложений (при их наличии) не позднее пяти рабочих дней с момента окончания проверки направляется гражданину заказным письмом с уведомлением о вручении, которое приобщается к экземпляру акта проверки, хранящемуся в деле органа муниципального земельного контроля.

4. В случае выявления в ходе проверки нарушения требований земельного законодательства, за которое законодательством Российской Федерации предусмотрена административная и иная ответственность, орган муниципального земельного контроля направляет копию акта проверки в орган государственного земельного надзора.

5. В случае выявления в ходе проверки нарушения требований земельного законодательства, за которое законодательством Республики Татарстан предусмотрена административная ответственность, привлечение к ответственности за выявленное нарушение осуществляется в соответствии с указанным законодательством.

Статья 8. **Права граждан при проведении проверки в рамках осуществления муниципального земельного контроля в отношении граждан**

Гражданин при проведении проверки в рамках осуществления муниципального земельного контроля в отношении граждан имеет право:

1) непосредственно присутствовать при проведении проверки, давать объяснения по вопросам, относящимся к предмету проверки;

2) получать от органа муниципального земельного контроля, его должностных лиц информацию, относящуюся к предмету проверки;

3) знакомиться с результатами проверки и вносить в акт проверки информацию о своем ознакомлении с результатами проверки, о согласии или несогласии с ними, а также с отдельными действиями должностных лиц органа муниципального земельного контроля;

4) обжаловать действия (бездействие) должностных лиц органа муниципального земельного контроля, повлекшие за собой нарушение прав гражданина при проведении проверки, в административном и (или) судебном порядке в соответствии с законодательством Российской Федерации.

Статья 9. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
13 октября 2015 года
№ 83-ЗРТ

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

1 статья. **Муниципаль җир контроле**

Муниципаль җир контроле дигәндә җир мөнәсәбәтләре объектларына карата Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында хокук бозулар өчен административ һәм башка җаваплылык каралган Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары таләпләрен дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның, гражданнарның үтәвен тикшереп тору буенча җирле үзидарә органнары эшчәнлеге аңлашыла.

2 статья. **Дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру**

1. Юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата муниципаль җир контроле, Россия Федерациясе Җир кодексында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына карата муниципаль җир контроле юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру**

1. Гражданнарга карата муниципаль җир контроле гражданнар җир мөнәсәбәтләре объектларыннан файдаланганда аларның Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары таләпләрен үтәвен планлаштырылган һәм планнан тыш тикшерүләр (алга таба – планлаштырылган тикшерү һәм планнан тыш тикшерү) уздырып гамәлгә ашырыла.

2. Планлаштырылган тикшерү иң еш дигәндә өч елга бер тапкыр, планлаштырылган тикшерүләр уздыруның муниципаль җир контроле органы тарафыннан раслана торган еллык планы (алга таба – еллык тикшерүләр планы) нигезендә үткәрелә.

3. Планлаштырылган тикшерүне еллык тикшерүләр планына кертү өчен нигез булып түбәндәгеләрдән соң өч ел узу тора:

1) гражданның җир мөнәсәбәтләре объектына (алга таба – җир кишәрлеге) хокукы барлыкка килгән көннән;

2) җир кишәрлегенә соңгы тапкыр планлаштырылган тикшерү тәгәлләнгән көннән.

4. Расланган еллык тикшерүләр планы кызыксынган затларга аны муниципаль җир контроле органының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән йә мөмкин булган башка ысул белән җиткерелә.

5. Планнан тыш тикшерү түбәндәге очракларда үткәрелә:

1) җир законнары таләпләрен бозуның ачыкланган очрагын бетерү хакында элек бирелгән күрсәтмәне граждан тарафыннан үтәү срогы чыкса;

2) муниципаль җир контроле органнарына гражданнардан, шул исәптән индивидуаль эшкуарлардан, юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүмат түбәндәге фактлар хакында булса:

а) гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зарар салу, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләтнең иминлегенә зыян китерү куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зарар салу, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләтнең иминлегенә зыян китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу.

6. Әлеге статьяның 5 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, әгәр алар буенча муниципаль җир контроле органына мөрәҗәгать иткән затны билгеләп булмаса, шулай ук әлеге статьяның 5 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү уздыру өчен нигез була алмый.

4 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерүләр оештыру тәртибе**

1. Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерүләр муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсе (боерыгы) нигезендә үткәрелә.

2. Муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсендә (боерыгында) түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) муниципаль җир контроле органының исеме;

2) тикшерү үткәрергә вәкаләтле вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерү үткәрү өчен җәлеп ителә торган экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, вазыйфалары;

3) тикшерү үткәрелә торган гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме;

4) тикшерү объекты булган җир кишәрлегенең (алга таба – тикшерелә торган җир кишәрлеге) идентификация билгеләре (җир кишәрлегенең адресы яисә, адресы булмаган очракта, җир кишәрлеге урнашкан урынны башкача тасвирлау, кадастр номеры, җир кишәрлеге керә торган җирләрнең категориясе);

5) тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре;

6) тикшерүнең төре (планлаштырылган яисә планнан тыш) һәм аны үткәрү рәвеше (документлар буенча яисә урынга барып);

7) граждан тапшырырга тиешле документларның исемлеге;

8) тикшерүне үткәрә башлау һәм төгәлләү датасы.

5 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә**

1. Муниципаль җир контроле органы планлаштырылган тикшерү үткәрү турында гражданга тикшерү үткәрелә башлаганчы кимендә өч эш көне алдан муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) планлаштырылган тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсе (боерыгы) күчермәсен тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат белән җибәреп яисә мөмкин булган башка ысул белән хәбәр итә.

2. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, муниципаль җир контроле органы планнан тыш тикшерү үткәрү турында гражданга тикшерү үткәрелә башлаганчы кимендә 24 сәгать кала мөмкин булган теләсә нинди ысул белән хәбәр итә.

3. Әгәр гражданның җир законнары таләпләрен бозуы аркасында гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зарар салынса, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә) зыян килсә, дәүләтнең иминлегенә куркыныч янаса, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килсә яисә барлыкка килү ихтималы булса, планнан тыш

тикшерү үткәрелә башлау турында гражданга алдан хәбәр итү таләп ителми. Бу очракта планнан тыш тикшерү үткәргәндә гражданның яисә аның вәкиленең булмавы тикшерү үткәрү өчен каршылык була алмый.

6 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерүләрнең рәвешләре**

1. Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерүләр документлар буенча һәм (яисә) барып тикшерү рәвешләрендә үткәрелә, аларның һәркайсын үткәрү срогы 20 эш көненнән артырга тиеш түгел.

2. Катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләр уздыру, махсус экспертизалар ясау таләп ителүгә бәйле аерым очракларда, тикшерү үткәрә торган затларның дәлилләнгән тәкъдимнәренә нигезләнеп, тикшерү срогы муниципаль җир контроле органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) күрсәтмәсе (боерыгы) белән озайтылырга мөмкин, ләкин 20 эш көненнән дә артыгракка түгел.

3. Документлар буенча тикшерү муниципаль җир контроле органы урнашкан урын буенча үткәрелә. Урынга барып тикшерү тикшерелә торган җир кишәрлегенең факттагы урнашу урыны буенча үткәрелә.

4. Документлар буенча тикшерү предметы гражданның тикшерелә торган җир кишәрлегенә хокукларын һәм бурычларын билгели торган документлардагы белешмәләрдән, шулай ук гражданның җир законнары таләпләрен үтәвенә бәйле документлардан гыйбарәт.

5. Документлар буенча тикшерү барышында иң элек муниципаль җир контроле органы карамагында булган документлар, шул исәптән алдагы тикшерүләр актлары, административ хокук бозулар турында эшләрне карау материаллары һәм гражданга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында элек үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре хакындагы башка документлар карала.

6. Муниципаль җир контроле органы карамагындагы документларда булган белешмәләрнең дөреслеге нигезле шик тудырса йә бу белешмәләр гражданның җир законнары таләпләрен үтәвен бәяләргә мөмкинлек бирмәсә, муниципаль җир контроле органы граждан адресына, документлар буенча тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны һәм аңлатмаларны тапшыруны таләп итеп, дәлилләнгән гарызнамә җибәрә. Дәлилләнгән гарызнамә алынган көннән алып 10 эш көне эчендә граждан муниципаль җир контроле органына гарызнамәдә күрсәтелгән документларны һәм аңлатмаларны тапшырырга тиеш.

7. Муниципаль җир контроле органы гражданнан документлар буенча тикшерү предметына карамый торган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук бу орган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарыннан, башка муниципаль контроль органнарыннан алырга мөмкин белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә тиеш түгел.

8. Документлар буенча тикшергәндә гражданның тикшерелә торган җир кишәрлегенә хокукларын һәм бурычларын билгели торган, муниципаль җир контроле органы карамагында булган документлардагы белешмәләрнең тулылыгын

һәм дөреслеген тикшереп карау йә гражданның җир законнары таләпләрен үтәвен бәяләү мөмкин булмаган очракта, урынга барып тикшерү үткәрелә.

9. Урынга барып тикшерү муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының хезмәт таныклыгын күрсәтүдән, гражданны җитәкченең (җитәкче урынбасарының) урынга барып тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсе (боерыгы) белән һәм урынга барып тикшерүне үткәрүче затларның вәкаләтләре белән, шулай ук урынга барып тикшерүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, тикшереп тору чараларының төрләре һәм күләме, экспертлар составы, урынга барып тикшерүгә җәлеп ителә торган эксперт оешмалары вәкилләре, тикшерүне үткәрү сроклары һәм шартлары белән таныштырудан башлана.

10. Граждан муниципаль җир контроле органының урынга барып тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларының һәм урынга барып тикшерүдә катнашучы экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең тикшерелә торган җир кишәрлегенә керә алуын тәэмин итәргә тиеш.

7 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе**

1. Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында муниципаль җир контроле органының тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлары тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре буенча тикшерү акты төзелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) тикшерү актын төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) муниципаль җир контроле органы исеме;

3) муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) тикшерүне билгеләү турында күрсәтмәсенең (боерыгының) датасы һәм номеры;

4) тикшерү үткәргән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазыйфалары;

5) тикшерү үткәрелгән гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме;

6) тикшерү үткәргәндә һәм тикшерү акты төзегәндә шунда булган затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

7) тикшерүнең башлану һәм тәмамлану датасы һәм вакыты, тикшерү үткәрү урыны;

8) тикшерү нәтиҗәләре, шул исәптән Россия Федерациясе законнарын, Татарстан Республикасы законнарын бозуларны ачыклау турында белешмәләр;

9) гражданның яисә аның тикшерү вакытында шунда булган вәкиленең тикшерү акты белән танышуы яисә танышудан баш тартуы турында, аларның имзалары булу яисә имза куюдан баш тартулары хакында белешмәләр;

10) тикшерү үткәргән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затларның имзалары.

2. Тикшерү акты тикшерү тәмамланганнан соң ук ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталарның (алар булган очракта) күчермәләре белән бергә тикшерү акты белән танышу йә танышудан баш тарту турында расписка белән гражданга яисә аның вәкиленә тапшырыла.

3. Тикшерү үткәргәндә граждан яисә аның вәкиле булмаса, шулай ук алар тикшерү акты белән танышу йә танышудан баш тарту турында расписка бирүдән

баш тарткан очракта, тикшерү актының бер нөсхәсе кушымталарның (алар булган очракта) күчермәләре белән бергә, тикшерү тәмамланган мизгелдән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат белән гражданга җибәрелә, хатның тапшырылуы турында хәбәр тикшерү актының муниципаль җир контроле органындагы делода саклана торган нөсхәсенә беркетелә.

4. Тикшерү барышында Россия Федерациясе законнарында административ һәм башка җаваплылык каралган җир законнары таләпләрен бозу ачыкланса, муниципаль җир контроле органы тикшерү актының күчермәсен дәүләт җир күзәтчелеге органына җибәрә.

5. Тикшерү барышында Татарстан Республикасы законнарында административ җаваплылык каралган җир законнары таләпләрен бозу ачыкланса, ачыкланган хокук бозу өчен җаваплылыкка тарту күрсәтелгән законнар нигезендә башкарыла.

8 статья. **Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерү үткәргәндә гражданнарның хокуклары**

Гражданнарга карата муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерү үткәргәндә граждан түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тикшерү үткәрелгәндә шунда булырга, тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләргә аңлатмалар бирергә;

2) муниципаль җир контроле органыннан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына кагылышлы мәгълүмат алырга;

3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актына тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы турында, алар белән, шулай ук муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының кайбер гамәлләре белән килешүе яисә килешмәве хакында мәгълүмат өстәргә;

4) муниципаль җир контроле органы вазыйфаи затларының тикшерү барышында гражданның хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә шикаять белдерергә.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2015 елның 13 октябре
№ 83-ТРЗ